КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 17 декабрь г.Казань № 1101

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче;

2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 30 май, 499 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 15 июль, 683 нче; 2022 ел, 12 август, 797 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче; 2022 ел, 20 сентябрь, 1018 нче; 2022 ел, 11 октябрь, 1093 нче; 2022 ел, 8 ноябрь, 1184 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1249 нчы; 2023 ел, 21 февраль, 171 нче; 2023 ел, 10 август, 968 нче; 2023 ел, 25 сентябрь, 1183 нче; 2023 ел, 1 ноябрь, 1390 нчы; 2023 ел, 18 ноябрь, 1487 нче; 2023 ел, 27 декабрь, 1696 нчы; 2024 ел, 10 апрель, 247 нче; 2024 ел, 11 июнь, 419 нчы; 2024 ел, 17 июнь, 431 нче; 2024 ел, 15 август, 659 нчы; 2024 ел, 4 сентябрь, 730 нчы; 2024 ел, 7 сентябрь, 741 нче; 2024 ел, 25 октябрь, 920 нче; 2024 ел, 31 октябрь, 951 нче; 2025 ел, 4 март, 132 нче; 2025 ел, 18 апрель, 247 нче; 2025 ел, 22 май, 345 нче; 2025 ел, 11 июль, 504 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6. Нормаль шартлардан тайпыла торган шартларда эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh_{med}}$), ($B_{kh_m}$) Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формулалар буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{kh_{med}} = O_b \times \frac{D_{kh_{med}}}{100\%} \times H_N,$$

монда:

$O_b$ – Татарстан Республикасы дәүләт медицина учреждениеләре хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база окладлары күләме;

$D_{kh_{med}}$ – Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр күләмнәре, процент;

$H_N$ – әлеге вазыйфа буенча эш күләме нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгать нормасы (1,0 ставка, 0,75 ставка, 0,5 ставка, 0,25 ставка һ.б.);

$$B_{kh_m} = D_{kh_m} \times H_N,$$

монда:

$D_{kh_m}$ – Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр күләмнәре, сум;

$H_N$ – әлеге вазыйфа буенча эш күләме нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары хезмәткәрләренең база оклады өчен сәгать нормасы (1,0 ставка, 0,75 ставка, 0,5 ставка, 0,25 ставка һ.б.).

Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә нормаль шартлардан читләшә торган шартларда эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләрнең тәкъдим ителә торган күләмнәре әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында китерелде.»;

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасындагы 157 юлының 4 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина пункты».

2. Бу карарның гамәлдә булуы (гамәле 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган ундүртенче һәм унбишенче абзацлардан тыш) 2024 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эл.Хөк., А.М.Сәгыйтова